**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2021 елның 16 апреле №35

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2021 елның 4 мартында 30 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2021 елның 4 мартында 30 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2.3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**